СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.03.2026 г.Лениногорск № 5

**Лениногорск муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 56 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законның 29 һәм 65 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 548-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Лениногорск муниципаль районы Советы карар КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 56 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.8.1 пунктының 5 пунктчасында «аларның вәкилләре,» сүзләреннән соң «контрольдә тотыла торган зат өчен үз-үзен җайга сала торган оешмада мәҗбүри әгъзалык каралган булса,» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының экология, табигатьтән файдалану, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы Башлыгы, Совет рәисе М.Н.Гирфанов